РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» декабрь 2023 ел г. Альметьевск № 8300

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы 531 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районында «Мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентны раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы 531 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 24 мартындагы 656 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче кушымтада карарга:

1 бүлекнең 1.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан), шулай ук катнашканда һәлак булучыларның (үлгәннәрнең) балалары».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып

заказ № 1-851

чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов